КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 2 октябрь г.Казань № 1211

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратлары структурасын һәм штат расписаниесен раслау турында» 2007 ел, 12 ноябрь, 626 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының җәмәгать судьялары аппаратлары структурасын һәм штат расписаниесен раслау турында» 2007 ел, 12 ноябрь, 626 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 21 декабрь, 738 нче; 2010 ел, 29 ноябрь, 957 нче; 2013 ел, 9 август, 556 нчы; 2013 ел, 11 декабрь, 976 нчы; 2014 ел, 17 март, 163 нче; 2016 ел, 14 гыйнвар, 11 нче; 2016 ел, 11 май, 294 нче; 2017 ел, 29 сентябрь, 732 нче; 2017 ел, 28 декабрь, 1069 нчы; 2018 ел, 19 февраль, 96 нчы; 2017 ел, 27 апрель, 302 нче; 2020 ел, 17 март, 194 нче; 2020 ел, 2 октябрь, 893 нче; 2020 ел, 30 декабрь, 1252 нче; 2021 ел, 30 декабрь, 1359 нчы; 2022 ел, 17 сентябрь, 1014 нче; 2022 ел, 30 декабрь, 1460 нчы; 2023 ел, 31 июль, 910 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының җәмәгать судьясы аппараты структурасының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җәмәгать судьясы ярдәмчесе»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының җәмәгать судьялары аппаратларының штат расписаниесен яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Бу карар 2023 елның 1 октябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2007 ел, 12 ноябрь, 626 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 2 октябрь, 1211 нче
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратларының
штат расписаниесе

| Вазыйфа исеме | Саны, берәмлек | Вазыйфаи оклады, тариф ставкасы, сум | Вазыйфаи окладлар, тариф ставкалары буенча хезмәт өчен түләүнең айлык фонды, сум |
|---|---|---|---|
| Җәмәгать судьясы ярдәмчесе | 190 | 20 657,0 | 3 924 830,0 |
| Суд утырышы секретаре | 190 | 20 657,0 | 3 924 830,0 |
| 2 разрядлы өлкән белгеч – канцелярия мөдире | 165 | 16 774,0 | 2 767 710,0 |
| 2 разрядлы белгеч | 176 | 15 962,0 | 2 809 312,0 |
| Барлыгы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре | 721 | - | 13 426 682 |
| Өлкән белгеч | 14 | 17 764,0 | 248 696,0 |
| 5 разрядлы машина йөртүче | 2 | 16 281,0 | 32 562,0 |
| Биналарга комплекслы хезмәт күрсәтү һәм ремонт ясау буенча 4 разрядлы эшче | 5 | 16 012,0 | 80 060,0 |
| Биналарга комплекслы хезмәт күрсәтү һәм ремонт ясау буенча 3 разрядлы эшче | 15 | 15 773,0 | 236 595,0 |
| Җитештерү һәм хезмәткәрләр бүлмәләрен 2 разрядлы җыештыручы | 64,5 | 15 522,0 | 1 001 169,0 |
| Барлыгы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына кертелмәгән хезмәткәрләр | 100,5 | - | 1 599 082,0 |
| Барысы җәмәгать судьялары аппаратлары буенча | 821,5 | | 15 025 764,0 |

______________________________